**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.01.2018 №12од

г. Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 29 декабрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» карары чыгу белән бәйле рәвештә, боерам:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән бүлмәләр турында» 2017 елның 29 декабрендәге 01-02/176 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык исемендә «депутатлары» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы» сүзләрен өстәргә»;

преамбулада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 24 июнендәге «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле орган турында» 436 номерлы карары сүзләреннән соң «,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмә сүзләрен өстәргә;

1 пунктның икнче һәм өченче абзацларында «депутатлары» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы» сүзләрен өстәргә»;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына сайлаучылар белән очрашулар өчен бүлмәләр бирүнең боерык белән расланган тәртибе исемендә һәм 1 пунктында «депутатлары» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы» сүзләрен өстәргә»;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән бүлмәләрнең боерык белән расланган исемлеге исемендә «депутатлары» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы» сүзләрен өстәргә».

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән урыннар турында» 2018 елның 11 декабрендәге 4 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык исемендә «депутатлары» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы» сүзләрен өстәргә;

преамбулада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 24 июнендәге «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле орган турында» 436 номерлы карары сүзләреннән соң «,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмә сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән урыннарның боерык белән расланган исемлеге исемендә «депутатлары» сүзе алдыннан «Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы» сүзләрен өстәргә.

3. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин